белгеч» вазыйфасы буенча билгеләнә һәм күрсәтелгән чыгымнарның агымдагы финанс елына i-муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган күләме нигезендә чираттагы финанс елына һәм план чорына хезмәт хакын арттыру индексларын кулланып исәпләнә.

I-муниципаль берәмлегендә эшкә сәләтсез затларга мөнәсәбәттә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең норматив саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән i-муниципаль берәмлегенең өлкән яштәге халкы саныннан чыгып билгеләнә.

I-муниципаль берәмлегенең өлкән яштәге халкы саны Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистика мәгълүматларын формалаштыру функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы белешмәләре буенча агымдагы финанс елына кадәрге елның 1 гыйнварына билгеләнә.»;

г) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. I-муниципаль берәмлегендә эшкә сәләтсез затларга мөнәсәбәттә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бер хезмәткәргә исәпләгәндә матди тәэмин итү чыгымнары, агымдагы финанс елына i-муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган матди тәэмин итү чыгымнары күләменнән чыгып, чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеш фаразының төп күрсәткечләре нигезендә индекс-дефляторлар кулланып исәпләнә.»;

3) 3 нче кушымтада:

а) 2 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$К_{1i}$ – i-муниципаль берәмлегендә чираттагы финанс елына һәм план чорына опекага (попечительлеккә) тапшырылган мәктәпкәчә яштәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның саны, ул чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләмен билгеләү елына кадәр тәгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлегендә әлеге категориядәге балаларның факттагы саны турында җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә шундый категориядәге балаларның еллык уртача саны буларак Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$К_{2i}$ – i-муниципаль берәмлегендә чираттагы финанс елына һәм план чорына опекага (попечительлеккә) тапшырылган мәктәп яшендәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның саны, ул чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләмен билгеләү елына кадәр тәгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлегендә әлеге категориядәге балаларның факттагы саны турында җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә шундый категориядәге балаларның еллык уртача саны буларак Татарстан Республикасы

башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.»;

б) 3 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$K_{1j}$ – i-муниципаль берәмлегендә чираттагы финанс елына һәм план чорына бала алган гаиләләргә тәрбиягә тапшырылган мәктәпкәчә яшьтәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның саны, ул чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләмен билгеләү елына кадәр тәгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлегендә әлеге категориядәге балаларның фактлагы саны турында җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә шундый категориядәге балаларның еллык уртача саны буларак Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$K_{2j}$ – i-муниципаль берәмлегендә чираттагы финанс елына һәм план чорына бала алган гаиләләргә тәрбиягә тапшырылган мәктәп яшендәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның саны, ул чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләмен билгеләү елына кадәр тәгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлегендә әлеге категориядәге балаларның фактлагы саны турында җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә шундый категориядәге балаларның уртача еллык саны буларак Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.»;

в) 4 пунктта:

бишенче – сигезенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$K_{1j}$ – i-муниципаль берәмлегендә чираттагы финанс елына һәм план чорына бала алган гаиләләргә тәрбиягә тапшырылган мәктәпкәчә яшьтәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның саны, ул чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләмен билгеләү елына кадәр тәгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлегендә әлеге категориядәге балаларның фактлагы саны турында җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә шундый категориядәге балаларның еллык уртача саны буларак Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә;

$K_{2j}$ – i-муниципаль берәмлегендә чираттагы финанс елына һәм план чорына бала алган гаиләләргә тәрбиягә тапшырылган мәктәп яшендәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның саны, ул чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенцияләр күләмен билгеләү елына кадәр тәгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлегендә әлеге категориядәге балаларның фактлагы саны турында җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә шундый категориядәге балаларның еллык уртача саны буларак Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә;

